РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ШЕМОРДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

0, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 3-21-44

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШӘМӘРДӘН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Шәмәрдән авылы, Лермонтов урам,
2 йорт
тел. (84362) 3-21-44

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
18.10.2023

КАРАР
№ 29

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының «Биналарга, корылмаларга, бүлмәләргә якын тирәдә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган урыннар турында» 25.03.2019 елгы №5 карарына үзгәрешләр кертү турында

РФ Хөкүмәтенең 09.06.2020 №841 «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану һәм этил спирты, алкогольле һәм спиртлы эчемлекләр җитештерү һәм әйләнеше өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда контроль буенча чаралар үткәргәндә үтәлергә тиешле мәҗбүри таләпләр булган башкарма хакимиятнең федераль органнарының кайбер актларын гамәлдән чыгару турында» Карарына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 25.03.2019 елның 5 нче номерлы «Биналарга, корылмаларга, бүлмәләргә якын тирәдә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган урыннар турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. "Җирле үзидарә органнары тарафыннан алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителмәгән кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү" кагыйдәләренең а) пунктчасының 2 пунктында күрсәтелгән (алга таба текст буенча –Кагыйдә), РФ Хөкүмәтенең 27.12.2012 №1425 карары белән расланган «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан алкоголь продукциясен ваклап сатуга рөхсәт ителмәгән гражданнарның күпләп җыелу урыннарын һәм югары куркыныч чыганаклары урнашкан урыннарны билгеләү, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында, анда алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми, этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга салу һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының 10

пунктчасында һәм 4.1 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән сүзләр белән алыштырырга» (алга таба текст буенча- Закон)»;

1. 2. б) пунктчасының 2 пунктында «Кагыйдәләрнең 2 пунктында» сүзен «Законның 16 статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасында һәм 4.1 пунктының беренче абзацында» сүзе белән алыштырырга;

1.3. 3 нче пунктта «Кагыйдәләрнең 2 пунктында» сүзен «Законның 16 статьясының 2 нче пунктының 10 нчы пунктчасында һәм 4.1 пунктының беренче абзацында" сүзе белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/rus/shemordan адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы А.К.Валиев